**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

КАРАР
от 19. 12. 2019

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ ПР- 323

**Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 15 февралендәге ПР-24 номерлы “Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм исәпкә алу турында” муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында” карарына үзгәрешләр кертү турында (балалар бакчалары)»**

2019 елның 2 декабрендәге «Россия Федерациясе Гаилә кодексының 54 статьясына һәм “Россия Федерациясендә мәгариф турында" Федераль законның 67 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" гы 411 – ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә карар бирәм:

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 15.02.2019 ел, № ПР-24 карары белән расланган Административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Регламентның 1.2 пунктын түбәндәге эчтәлекле 19 яңа абзац өстәргә:

"Бер гаиләдә яшәүче һәм гомуми яшәү урыны булган балалар мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программалары буенча укырга өстенлекле кабул итү хокукына ия, аларда энеләре һәм (яисә) сеңелләре белем ала".

2.6 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«мәктәпкәчә белем бирү оешмасы белән ата-аналар килешүе;

- белешмә (гаилә составы һәм теркәлү турында йорт китабыннан өземтә)"

2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмати рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Ф.Нурлыевага йөкләргә.

Җитәкче И.И.Габдулхаев